СОВЕТ КУРКАЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п.ж.д.рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОРКАЧЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык тимер юл разъезды пос., Гагарин ур., 7

Тел./факс 8(84365) 71-2-15, e-mail:Kurk.Vsg@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18 июль 2022 ел** **№ 45**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 144 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында (Советның 07.08.2020 № 157, 15.01.2021 N15 карарлары редакциясендә), әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Коркачык авыл җирлеге Советының 2021 елның 05 октябрендәге 33 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Коркачык авыл җирлеге Советының 2021 елның 05 октябрендәге 33 нче номерлы « «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карары нигезендә 2021 елның 25 октябрендәге 10:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык тимер юл разъезды поселогы, Гагарин урамы, 7 нче йорт үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл

җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 144 номерлы карары белән кабул ителгән ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (Советның 07.08.2020 № 157, 15.01.2021 N15 карарлары редакциясендә) проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Салихҗанов